Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
**КАРАРы**

30 июня 2020 ел №13

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Торак кодексының 156 һәм 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта хезмәт күрсәтүләр һәм идарә итү, тоту һәм ремонт эшләре башкарылган очракта, торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен тиешле сыйфатсыз һәм (яисә) билгеләнгән дәвамлылыктан артып китүче өзеклекләр белән үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 декабрендәге 1097 номерлы карарын үтәү өчен,

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен 2020 елның 01 июленнән 2021 елның 30 июненә кадәр расларга һәм гамәлгә кертергә. (1 нче кушымта).
2. Түбән Мактама бистә башкарма комитетының карарын үз көчен югалткан дип танырга:

«Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен гомуми җыелышта 2019 елның икенче яртыеллыгында һәм 2020 елның беренче яртыеллыгында халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» 2019 елның 13 июнендәге 8 номерлы карары;

«Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен гомуми җыелышта 2019 елның икенче яртыеллыгында һәм 2020 елның беренче яртыеллыгында халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен түләү күләме турында» Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистә башкарма комитетының 2019 елның 13 июнендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 августындагы 14 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Түбән Мактама шәһәр тибындагы бистәсе, Тихоновка авылы торак пунктлары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 01 июленнән үз көченә керә, ә 1 нче кушымтаның 10 һәм 12 нче юллары 2020 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Түбән Мактама бистә башкарма
комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафикова

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистә
башкарма комитетының
30 июнь 2020ел № 13
карары белән расланган
1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучылары өчен, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау һәм күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өчен торак урынны карап тоту һәм ремонтлау турында карар кабул итмәгән, гомуми җыелышта халык өчен торак урыннарны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен 2020 елның 01 июленнән 2021 елның 30 июненә кадәр билгеләү турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләр өчен түләү күләме

| № п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Үлчәү берәмлеге | Айлык тариф |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | сум/кв. м | 2,33 |
| 2. | Гомуми файдаланудагы йорт эчендәге урыннарны җыештыру | сум/кв. м | 1,56 |
| 3. | Йорт яны территориясен җыештыру | сум/кв. м | 2,22 |
| 4. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмаларсыз торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | сум/кв. м | 2,33 |
| 5. | Автомат рәвештә бикләнә торган җайланмалары булган торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү (күпфатирлы йортта гомуми мөлкәт составында булганда) | сум/кв. м | 2,72 |
| 6. | Салкын су белән тәэмин итү приборлары белән йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 2,18 |
| 7. | Салкын су белән тәэмин итү приборларыннан башка йорт эчендәге инженерлык салкын су суүткәргеч-канализация челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | сум/кв. м | 1,99 |
| 8. | Газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,20 |
| 9. | Электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау һәм карап тоту | сум/кв. м | 0,82 |
| 10. | Торак биналарны капиталь ремонтлау | сум/кв. м | 6,11 |
| 11. | Дератизация | сум/кв. м | 0,15 |
| 12. | Найм торак урыннары (яллаучылар өчен) | сум/кв. м | 6,11 |

Түбән Мактама бистә башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р. Нафикова